Әссәламегаләйкем, кардәшләр-милләттәшләр! * Əssəlamegaləikem, qardəşlər-milləttəşlər!

اَسَّلام عليكم، قاردەشلار، ميللەتتەشلار!

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 ЕЛНЫҢ 12 МАРТЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА.

Бөтендөнья татар Конгрессына махсус чыгарылыш. Июнь, 1992 ел.

ТАТАРСТАННЫҢ ДӘҮЛӘТ ГЕРБЫ

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАННЫҢ ДӘҮЛӘТ ФЛАГЫ

И Казан, нурлы Казан!

ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ, МИЛЛӘТТӘШЛӘР!

Минтимер ШӘЙМИЕВ,
Татарстан Республикасы Президенты.

Бөтендөнья татар конгрессын үткәрү нигә кирәк булды соң? Бу сорауны миңа шактый еш бирәләр.

Җавап мондый: киң колачлы форумның зарурлыгы иҗтимагый үсештә милли фактор үзен һаман саен ныграк сиздерә барудан, чын мөстәкыйльлеккә омтылу заман таләбе булып әверелүдән килеп чыкты. Татар халкын да язмыш дөньяның төрле төбәкләренә таратты, үз милли мәдәниятенең төп үзәкләреннән аерды. Менә шуның өчен дә бөтендөнья татарлары өчен бүген туган телне, гореф-гадәтләрне, традицияләрне торгызу һәм үстерү, игътисади, мәдәни элемтәләрне киңәйтү һәм үстерү мәсьәләләре бик тә мөһим. Бөтендөнья татар конгрессы шушы мәсьәләләрне зур кызыксыну белән тикшерүне күздә тотып чакырылды да.

Җөмһүриятебездә йөздән артык милләт вәкиле яши. Татарлар 1.765.4 (48, 5 процент), руслар 1.575.4 мең (43,3) кеше. Аннан кала чувашлар, украиннар, мордвалар, марилар, башкортлар, белоруслар, еврейлар күпчелекне тәшкил итә. Шунысын куанып әйтә алабыз: җөмһүриятебездәге барча милләт халыклары да гасырлар дәвамында дус булып яшиләр, нәкъ менә шушы дуслык безгә халык хуҗалыгы тармакларында тотрыклы үсеш тәэмин итте. Милләтләр дуслыгы — ул бездәге иң зур байлык. Һәм аның кадерен белергә, аны сакларга кирәк. Хезмәт кешесе кулындагы сәяләр — русмы ул, башкортмы, маримы, мордвамы, татармы — берүк төсле. Ул куллар тормышыбызны бизәү максатыннан бары тик тыныч хезмәт кораллары гына тотсын өчен барысын да эшләргә кирәк. Май ае урталарында үткәрелгән Татарстан халыклары корылтаенда да шушы фикер кызыл җеп булып сузылды. Җөмһүриятебездә милләтара мөнәсәбәтләрнең тотрыклы булуын 21 мартта үткәрелгән референдум йомгаклары да исбатлады. Референдумда сайлау хокукы булган гражданнарның 82 проценты катнашкан иде, аларның 61,4 проценты Татарстанны цивилизацияле, демократик юл белән яңарту курсын яклап тавыш бирде. Шулай итеп, кайбер даирәләрнең көчле, тупас басымына карамастан, республикада яшәүчеләр олы гакыл, зур түземлелек күрсәттеләр.

Референдум нәтиҗәләре безгә зур мөмкинлекләр дә ача. Халыкара һәм республикаара традицион мөнәсәбәтләрне саклау аеруча әһәмиятле. Татарстан аларның барысы белән дә диярлек икътисади һәм социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча килешүләр һәм шартнамәләр төзеде. Аңлашыла ки, Татарстанның үз өстенә алган йөкләмәләрен нәтиҗәле үтәве өчен махсус оештыру структуралары кирәк. Аларның ролен Татарстан Республикасының нәкъ менә БДБ илләрендә һәм чит илләрдә ачыла торган Вәкиллекләре үтәр. Төзеләчәк Татарстан элемтәләрне үстерү, Татарстан Республикасының Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге илләре һәм чит ил дәүләтләре белән хезмәттәшлеге турындагы килешүләрне һәм шартнамәләрне гамәлгә ашыру максатларында Югославия, Согуд Гарәбстаны, Сүрия, Венгрия, Чехо-Словакия, Япония һәм башка илләрнең вәкилләре белән күп кенә мәсьәләләр буенча үзара файдалы сөйләшүләр алып барыла. Әле күптән түгел генә безнең делегация АКШта, Канадада, Швейцариядә булып кайтты.

Алда әле күп кенә халыкара оешмалар белән сөйләшеп килешәсебез бар.

Россия, Украина, Кыргызстан, БДБнең башка илләре белән Тышкы игътисады һәм сәяси элемтәләр министрлыгы бу эшнең үзәгенә әверелергә тиеш. Җөмһүриятебезнең тышкы сәяси һәм тышкы икътисади эшчәнлеген үткәрү өчен шушы министрлык җаваплы булачак. Шундый дәүләт органын булдыру — ә ул профессиональ яктан әзерлекле кадрлардан торачак — иң якын киләчәктәге бурычыбыз.

Бүген без һәр халыкта үз үткәненә игътибарның бермә-бер артуын күрәбез. Бу хәл, күрәсең, байтак дәрәҗәдә хәзерге җәмгыять тормышында тирән үзгәрешләр йогынтысында халыкларның милли үзаңы уянуы белән бәйләнгәндер. Үзләренең үткәненә әйләнеп кайтып, алар аннан бүгенге яшәешләре өчен үрнәк тә, гыйбрәт тә алалар. Узгандагы иҗтимагый-сәяси һәм рухи-мәдәни тәҗрибә замандашлар өчен үзенә бер тормыш мәктәбенә әверелә. Безнең татар да күпгасырлык тарихына мөрәҗәгать итеп, аннан күп нәрсәгә өйрәнә. Чөнки үткәнебез безнең үрнәк тә, сабак та алырлык. Ничә гасырлар буе мөстәкыйль дәүләт булып яшәгән халкыбызның аңына дәүләтчелек идеясе нык сеңгән. Аның тарихи аңы шул рәвешчә формалашкан. Хәтта үз мөстәкыйль дәүләтен югалтканнан соң да дәүләтчелек идеясе аның аңында, канында яши, рухына көч-куәт биреп тора. Вакыт халыкның тарихи аңында яшәгән дәүләтчелек идеясен тагын да көчәйтә генә төшә. Шуның бер чагылышы итеп, халкыбызның мөстәкыйль дәүләтчелеген тергезү, аякка бастыру өчен алып барган актив көрәшен күрсәтергә була. Шул актив көрәш нәтиҗәсендә җөмһүриятебез парламенты 1990елның 30 августында Дәүләт суверенитеты турындагы декларацияне кабул итте.

Җөмһүриятебездә тынычлык — барыннан да элек, татар һәм рус халыкларының, башка халыкларның бер-берсе белән аңлашып, ихтирам итешеп яшәүләренең нәтиҗәсе. Татар халкының күп өлеше җөмһүриятебездән читтә — Россиядә яши. Без ул төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезнең милли ихтыяҗларын канәгатьләндерү белән бер үк вакытта аларның рус халкы белән үзара аңлашып, дус яшәүләрен телибез.

Һичшиксез: Татарның бу беренче халыкара мәҗлесенә ватандашларыбыз билгеле бер өметләр белән җыела. Татарны милләт буларак саклау һәм яшәтү белән бәйле мондый мәсьәләләр, аларны хәл итү юллары турында конгресста җитди һәм эшлекле сөйләшү булуын теләр идем.

БЕЗНЕ КОТЛЫЙЛАР

Татарстанның мөстәкыйльлеге турында референдум уңаеннан дөньяның төрле почмакларыннан котлаулар килде.

Киң җәмәгатьчелек татар халкының референдумын хуплый.

Гали АКЫШ,
Бөтендөнья татар
лигасы Президенты.
Мюнхен шәһәре.

* * *

Референдум йомгакларын канәгатьләнү белән кабул иттек. Ул мөстәкыйль Татарстан Республикасында күп милләтле халыкларның тормыш шартларын яхшыртыр һәм икътисадын үстерер, гасырлардан килгән дуслыкны ныгытыр дип ышанабыз. Җөмһүрият халыкларының рухи мәдәнияте һәм сәясәте чәчәк атуын Аллаһы тәгалә насыйп итсен.

Мөфти **Тәлгать ТАҖЕТДИН.**
Уфа каласы.

* * *

Татарларга да, башка мөстәкыйль дәүләтләр белән бергә, халкына, туфрагына, диненә һәм дә гореф вә гадәтләренә хуҗа булырга вакыт җитте. Чөнки безләр дә кемнәрдән дә ким түгелбез. Ят илләрдә, сезләрдән еракта булсак та, күңелләребез сезнең берлән йөридер.

Бөтен эшләрегездә тагын да уңышлыклар теләп, хушисән булуыгызны Аллаһыбыздан теләп калабыз.

Канададагы татар җәмгыяте исеменнән **Талип КДЕКИ.**

* * *

Татарстан халкын җиңү белән котлап, бергә шатланабыз. Уңышлар, нык сәламәтлек, тынычлык сөюче барлык халыклар белән дуслык телибез.

Халыкара Кеше хокуклары җәмгыятенең Төньяк-Кавказ бүлеге комитеты.

* * *

Референдумның уңай нәтиҗәләргә ирешүе белән тәбрик итәбез. Республика халыкларына киләчәктә дә уңышлар насыйп булсын!

Чечен республикасы аксакаллары.

* * *

Без, чит илләрдә яшәүче татарлар, Татарстанның мөстәкыйль, бәйсез дәүләт булуын телибез. Шунлыктан безнең теләк сезнеке белән бер булып, газиз милләттәшләребезгә уңышлар һәм хәерле нәтиҗәләр теләп калабыз.

Америка Татар җәмгыяте исеменнән **Сәет КИЛКИ.**

* * *

Татарстан мөстәкыйль дәүләт булыр дигән өмет белән яшибез. Иншалла!

ХИСАМЕТДИННАР гаиләсе.
Финляндия.

Ватанпәрвәрләр кирәк

1989 елда Америкага килгән чагында казакъ әдибе Олжас Сөләйманов: «Инкыйлабка кадәр без, төрки халыклар, һәммәбез дә бер-беребезне аңлый идек. Инкыйлабтан соң безгә егермедән артык язу машинкасы бирделәр, әлифбаларыбызны аерып куйдылар. Нәтиҗәсе шул булды: без хәзер бер-беребезне аңлый да, бер-беребезнең язган язуларын укый да алмыйбыз», — дигән иде. Ул чакта төрки халыкларны аерган булсалар, бүген инде без татар милләтен дә шулай вак кисәкләргә бүлгәләргә маташабыз.

Егерменче гасыр башында Россиядәге кайсыбер милләтләр империя кысасыннан чыгып, бераз алга атлаган булсалар да, бүгенге көндә, демократиягә нисбәтән караганда, аларның барчасының да статусы бер чамада. Яңа җәмгыять, яңа дәүләт корылышы эшенә алынган һәр милләт әлегә юл башында гына. Хәл болай булганга, инде киләчәктә кайсы милләтнең алгарак чыгып, лидерлык ролен алуы көн тәртибенә килеп басачак. Минемчә, төптән уйлаганда, Татарстанның интеллектуаль мөмкинлекләре һич кенә дә Россияненеккеннән ким түгел. Милләт буларак формалашу чорын кичергән, үз дәүләтчелеген корган, ислам дине культурасын үзләштергән, күпме генә кимсетүләргә дә карамыйча, 440 ел буена күңеленә коллык хисе иңдермичә, таза рухын саклаган бер милләтнең дөрестән дә милли азатлык юлына, демократия тарафына чагыштырмача тизрәк күчүе бик тә мөмкин. Ләкин моның өчен халыкны туры юлга әйдәүче, аның мөмкинлекләрен белеп һәм аңлап туры юлга җибәрүче ватанпәрвәрлар, олы акыллы, курыкмас лидерлар кирәк.

Рифат ТАБИ,
профессор.
АКШ, Нью-Йорк.

Онытмагыз, милләтле без!


Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ,
Г. Тукай исемендәге Татарстан дәүләт бүләге лауреаты

Җир күчкәнбез,
Ил кичкәнбез,
«Аh» — эчкән без,
«Ваh» — эчкән без,
Болгар иле орлыгыннан
Кабат тишелеп үскәнбез,
Бөтен дөнья татарлары,
Онытмагыз, милләтле без.
Башкаларга милләтебез
Белән генә кыйммәтле без.
Чәчелгәнбез,
Сибелгәнбез,
Түгелгәнбез,
Таралганбыз —
Барыбер уртак Казанга
Юлны әле табалганбыз, —
Бөтендөнья татарлары,
Онытмагыз, милләтле без.
Башкаларга милләтебез
Белән генә кыйммәтле без.

Ватылганбыз,
Атылганбыз,
Сатылганбыз,
Аh органбыз, —
Барыбер дә Идел-Йортка
Туганнарны чакырганбыз.
Бөтен дөнья татарлары,
Онытмагыз, милләтле без.
Кешелеккә милләтебез
Белән генә кыйммәтле без.
Анда поскан,
Монда поскан,
Анда кыскан,
Монда кыскан —
Ә барыбер уртак табын
Җыя алды Татарстан;
Бөтен дөнья татарлары,
Онытмагыз, милләтле без.
Башкаларга милләтебез
Белән генә кыйммәтле без.

Борынгы Болгар җире — изге җир.

ФӘН БЕЛӘН ХЕЗМӘТНЕ БӘЙЛӘП



Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсендә быел беренче продукция алынуга 25 ел тула. Берләшмә, ай үсәсен көн үсеп, бик тиз илебез горурлыгына, каучукны иң күп җитештерүче нефть химиясе флагманына әверелде.

Продукцияне күп кенә түгел, ә сыйфатлы да җитештерә ул. «Нефтехим» берләшмәсе элеккеге тармак министрлыгы предприятиеләре арасында югары сыйфат өчен халыкара «Алтын Меркурий» медаленә лаек булган бердәнбер коллектив. Дөнья базарында алар җитештергән каучукка сорау хәзер дә бик зур. Бүген берләшмәнең 15 төрдәге продукциясе чит илгә сатыла. Күптән инде аның сыйфатына дәгъва белдерүче юк, киресенчә, үзара хезмәттәшлек элемтәләре урнаштырырга теләүчеләр саны арта бара.

Әлбәттә, бүгенге кыенлыклар Түбән Кама нефтехимикларын да читләтеп үтмәде. Ләкин шундый шартларда да былтыр алар товарлыклы продукция эшләп чыгару, табыш алу, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү планнарын арттырып үтәде. Бу уңышлар иң элек фән белән хезмәтне бәйләп, производствога фәнни-техник прогресс казанышларын киң кертүгә даими игътибар бирү нәтиҗәсе булып тора.

Алар базарга да ашык-пошык кына кермиләр, бөтен хәстәрлекне алдан күрәләр. Алга киткән капиталистик илләр белән чын икътисади ярыш оештырырга уйлыйлар. Шул максаттан үзләренең белгечләрен АКШ, Венгрия һәм башка илләрдәге менеджерлар хәзерләү курсларында укыталар.

Берләшмәнең тарихы — аның генераль директоры Гаяз Җәмик улы Сәхаповның да тормыш юлы. Ул берләшмәне, берләшмә аны үстерде. 1965 елда КХТИны тәмамлап килгән яшь белгеч цех механигы, цех начальнигы, заводның баш инженеры һәм директоры, берләшмәнең баш технологы һәм баш инженеры кебек җаваплы хезмәт баскычларын үтеп, 1985 елдан бирле дөньякүләм зур әһәмият тоткан гигант берләшмәне җитәкли. Җитәкче һәм Татарстан Республикасы халык депутаты буларак, предприятиенең һәм шәһәрнең социаль йөзен үзгәртүгә гаять зур өлеш кертә.

И. ЗАРИПОВ.

Рәсемнәрдә: берләшмәнең генераль директоры Г. Сәхапов һәм предприятиенең тышкы күренеше.

ХАЛКЫБЫЗ ТУРЫНДА

... Татарлар — горур, даншөхрәт сөючән, кунакчыл, сәүдә эшенә сәләтле һәм чисталык яратучан халык. Алар шулай ук укымышлы да, төрле хорафатларга аз ышаналар, үзләрендә бераз мактанчыклык та бар, үзара дус-тату яшиләр, кешегә ярарга, аның күңелен күрергә тырышалар, һәр нәрсәдә уртаклыкка омтылалар. Һәм алар эш сөючәннәр...

Карл ФУКС.

* * *

Мин, карт солдат буларак, фронтта татар сугышчыларын һәм командирларын күп күрдем һәм аларның корыч ихтыярына, чыдамлыгына һәрвакыт соклана идем.

Советлар Союзы Маршалы **Р. Я. МАЛИНОВСКИЙ.**

* * *

Дөнья һәм дөнья әдәбияты исемнәре иҗатларының мәңгелек данына әйләнгән күп кенә шагыйрьләрне беләм. Ләкин шагыйрь һәм герой Муса Җәлил кебек, әсәрләре белән генә түгел, бәлки үлеме белән дә исемен мәңгеләштергән шагыйрьләр бик аз. Менә алар: бөек Байрон, Венгриянең данлыклы шагыйре Петефи, герой Юлиус Фучик һәм, ниһаять, Муса Җәлил.

Сәмәд ВУРГУН.

* * *

«... көрәшләрдә чыныккан һәм мөстәкыйльлек өчен көрәшен дәвам иттерүче халыкның (татар халкының — **ред.**) үзенә килгәндә, психологик яктан җитәрлек дәрәҗәдә дәүләтчел халык ул.»

Г. ИСХАКЫЙ.

* * *

Татар халкының борынгы «Былбылым» дигән көе, бигрәк тә аның икенче өлеше японнарның «Дүрт фасыл җыры»на бик тә охшаган. Халык җырларының кушымтасы да безне бик берләштерә. Ул японнарның атлар куып баручылар җырын хәтерләтә. Мөгаен, бу табигыйдер дә, чөнки милли аспектта татарларның да, японнарның да борынгы бабалары берүк булган ич. Ерак җирләрдән шундый җырларны ишеткәч, көтмәгәндә күңелдә җылы хисләр уяна.

Мэйдзи КОХАТО.

* * *

Тукай җыры безнең белән килде,
Җыры ялкын аның бүген дә.
Тукай... ул бит безнең якты йолдыз
Поэзиянең аяз күгендә.

Мостай КӘРИМ.

* * *

... Татарлык — чиксез рухи дөнья ул. Шуңа күрә бер талпынуда гына аны бөтенләе белән танып-белүне күз алдына да китереп булмый. Без эш-гамәлләребездә, теләк-ихтыяҗларыбызда аңа тартылсак, үз асылыбызга кайтканда аның шифалы җилен тойсак, менә шунда ул яшәеш мәгънәсе, чикләнгәлекне җиңү, безнең мәңгелеккә илтәсе юлыбыз...

Тәфкил КАМАЛ,
философия фәннәре кандидаты.

БӘЙСЕЗЛЕКНЕҢ ИКЪТИСАДИ НИГЕЗЛӘРЕ

Мөхәммәт САБИРОВ,
Татарстан Җөмһүриятенең Премьер-министры.

Татарстан халкы 1992 елның 21 нче мартында үткәрелгән референдумда Россия белән мөнәсәбәтләрне тигез хокуклы килешү нигезендә алып барырга тавыш бирде. Ләкин еш кына Татарстан юкка тыпырчына, ул Россиядән башка яши алмаячак, дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Без Россиядән һәм БДБ составына кергән башка республикалардан аерылып яшәргә җыенмыйбыз. Максатыбыз тигез хокуклы килешүләргә таянып эш итү. Ә инде җөмһүриятебезнең икътисади хәленә килгәндә, Татарстан башка республикалардан һич тә ким-хур түгел. Бу турыда түбәндәге саннар әйбәт сөйли.

Республикада җитештерелгән милли доход 1991 елда, якынча мәгълүматларга караганда, 16,7 миллиард сум тәшкил итте. Бу күрсәткеч ягыннан республика Әрмәнстан, Латвия, Литва, Молдова, Таҗикстан, Төркмәнстан, Эстония кебек элекке союздаш республикаларны да узып китә.

Татарстан продукциясе барлык элекке союздаш һәм автономияле республикаларга, Россиянең барлык өлкәләренә һәм крайларына, дөньяның 80 нән артык иленә җибәрелә, ягъни икътисади үзара элемтәләрдә тора. Чит ил малтабарларының безгә бик теләп килүләре, хезмәттәшлек итәргә, үз капиталларын салырга әзер торулары — очраклы хәл түгел. Әмма аларны еш кына Татарстанның дәүләт статусы аның булмау туктатып кала.

Татарстанның шактый зур табигый һәм чимал ресурслары бар. Хәзерге вакытта республикада нефть запаслары 800—900 миллион тонна дип исәпләнә. Еллык нефть чыгаруны 25 миллион тонна дәрәҗәсендә тотканда, бу запаслар байтакка җитәр. Киләчәктә халык хуҗалыгына табигый битум да өстәләр. Битум запаслары 12 миллиард тонна һәм аннан да күбрәк дип исәпләнә.

Җан башына күчереп исәпләгәндә, Татарстанда промышленность продукциясе күләме Россия Федерациясендәгегә караганда 20,3 процентка, авыл хуҗалыгы продукциясе күләме 20,6 процентка күбрәк.

Республика продукциянең үтә мөһим төрләрен җитештерү буенча илдә алдынгы позицияләрне тота. Мәсәлән, изопрен каучукның 40 процентын, бутил каучукның 75 процентын, полиэтиленның 34 процентын, шиннарның 25 процентын, кино-фотопленкаларның 46 процентын, магнитлы тасмаларның 23 процентын җитештерә. Илдәге йөк ташуларның 80 проценты КамАЗ автомобильләренә туры килә.

Тулаем исә республиканың продукция чыгаруда һәм кертүдә уңай сальдосы бар. Татарстан халык куллануы товарларын елына 5 миллиард сумлыктан артык җитештерә, әмма аларны җитештерүче предприятиеләргә үзе хуҗа булмаганга күрә, товарларның күп төренә кытлык кичерә. Шул ук вакытта 1990 елда товар чыгаруның һәм кертүнең гомуми уңай сальдосы булган килеш республикага башка төбәкләрдән 6,1 миллиард сумлык чимал, халык куллануы товарлары һәм материаллар кертелде.

Үз республикабызның тышкы элемтәләр министрлыгы, тышкы экономик банкы, тышкы икътисади эшчәнлек буенча үз законы булса, дәүләт дәрәҗәсендә танылуыбыз өчен мөмкинлек күбәер иде, әлбәттә. Ә бит моның өчен нигез бар бездә. Әйтик, Түбән Кама «Нефтехим», һәм «Шин», Казан «Органик синтез» һәм «Оптика-механика» заводы» берләшмәләрен, Чаллыдагы «КамАЗ» акционерлык җәмгыятен дөньяда яхшы беләләр.

Хәзер Татарстан юрисдикциясенә 100 дән артык промышленность, төзелеш, транспорт предприятиесе һәм оешмасы күчерелде. Безнең предприятиеләрнең чагыштырма өлеше 2 проценттан 56 процентка кадәр үсте.

Без республика территориясеннән ала торган керемнәр Үзәккә китеп барды һәм безгә бик кимсетелгән рәвештә генә кайтарылды. Мәсәлән, 1991 елда Татарстан территориясендә 7,98 миллиард сум күләмендә салым керемнәре җыеп алынды, җыемта чыгымнар 6,9 миллиард сум тәшкил итте, ягъни керемнәр чыгымнардан 1 миллиард сумга күбрәк булды. Бу сумманың бөтенесен Мәскәү үзенә алды.

Исәп-хисаплар шуны күрсәтә, дәүләтчелекне торгызуның төп принципларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә Татарстан Республикасының җыелма керемнәре даими үсә барырга һәм 7 миллиард сумнан да артып китәргә мөмкин. Үз чиратында чыгымнар да артачак һәм 6 миллиард сумнан күбрәкне тәшкил итәчәк, ягъни республика үз-үзен яшәтә алачак.

Зур ышаныч белән әйтергә мөмкин: республиканың икътисади потенциалы, аның халкының гасырлар буенча килгән хезмәт сөючәнлеге һәм булдыклылыгы Татарстанның Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенә кергән дәүләт берәмлекләре статусына тигез статус белән мөстәкыйль яши алуы мөмкинлеген гарантияли.

Мөстәкыйль җөмһүриятебезнең тышкы элемтәләре көннән-көн ныгый. Чит ил делегацияләрен кабул итәбез, үзебезнең делегацияләр дә чит илләрдә була. Күптән түгел, әйтик, җөмһүриятебезгә Төркиянең «Дегерэ» фирмасы президенты Дегер Эртург килгән иде. Аны Премьер-министр Мөхәммәт Сабиров та кабул итте. Бу рәсемдә Татарстан Министрлар Кабинетында сәүдә һәм промышленность экспорты турындагы килешүгә кул кую вакыты сурәтләнә.

А. Андронов фотосы.

Җидегән чишмә моңы

(Гомәр Бәширов иҗатында шигърият)

Шагыйрь-әдипләрнең җанга газиз иҗат җимешләре күп була. Әмма күпләр арасыннан шуларның берәве иҗатчының рухи туграсына әйләнеп китә. Шул бер әсәре укучы күңелендә әдипнең иҗат кәгъбәсе, җан моңы булып сызылып кала:

Җидегән чишмәләргә йөзек салдым,
Җидегән йолдыз күреп калсын дип.

«Проза» сүзе үзе үк тормышта поэзиянең капма-каршысы — антиподы. «Картайдык, безнең тормыш инде тоташ прозага әйләнде», дигәннәре бар кайбер картларның.

Ә бу аксакал, гомеренең тугызынчы дистәсен ваклагач, бер киң сулыш алып,— «икенче яшьлеген» башлый диярсең — прозасында да шигърият «дулкынына» күчә!

Күпне сөйли ул Җидегән чишмә!

Гомәр ага Бәширов, минемчә, хикәя, повесть, романнарыннан тыш, шул бер «Җидегән чишмә» җырының сүзләре белән генә дә шагыйрьләр арасында танылган булыр иде. Ул барыннан да элек лирик-психологик проза, шигърияткә якын хикәяләү остасы.



Аның турында, аның шәхесе, әсәрләренең гомумкешелек әһәмияте, язучының иҗат юлы, осталыгының серләре хакында шактый күп язылган инде. Мин бу олуг диңгез каршында саңгырауланган бер мосафирдай гаҗизмен. Әмма мине бу каләм остасының бөтен иҗатының, аеруча алтмышынчы-җитмешенче елларда язылган «Туган ягым-яшел бишек» повесте (1967), «Җидегән чишмә» (1977) романнарының тоташ шигърият белән сугарылуы искиткеч сокландыра. Аларда халкыбызның бетмәс-төкәнмәс рухи мөлкәте тәңкәләп-җайлап салынган.

Бу олы иҗат инде ничә буынны тәрбия кылды, мин исә бу олуг иҗат мәктәбе бигрәк тә авылны тәрбияләде дип әйтергә җөрьәт итәм. Чөнки «Намус»тагы Нәфисә, Мәүлиха, Әпипә, Карлыгачлар, безнең, сугыш елы малайларының әниләре, апалары иде.

Әле олы иҗатының башында беренчеләрдән булып ачылган чишмәсе — «Сиваш» (1937) повестенда Гомәр Разинның (кырыгынчы еллардагы псевдонимы) психологик портрет остасы, хәтта авыл инешендәге бака тавышларын үзәкне өзгеч моң белән тасвирлаган оста әдип — рәссам икәнен без малайлар укып белгән идек инде. Мондый осталыкка ирешү өчен иң әүвәл авылның җанын тыңлау кирәктер. Бөек Тукайны биргән мәшһүр Казан артында — Арча төбәгенең Яңасала авылында дөньяга килеп, остабикәдә, авыл мәдрәсәсендә гыйлем алып, унөч яшеннән чит авылларда кием тегеп йөрүченең өйрәнчеге булып китүләр бер дә эзсез калгандыр, димсез? Югыйсә, халыкның иҗат хәзинәсе, күңел көзгесе булган мәзәкләрен («Туксан тугыз мәзәк», «Мең дә бер мәзәк») кайдан табар идең?

Бу иҗатны бер-берең әяреп мактарга түгел,— ул инде аннан ашкан, диясе килә — аны бары укырга, укырга, өйрәнергә генә, үзеңнән соң килгәннәргә дә мирас итеп тапшыру кирәктер.

Бу мирас безнең әбиләрнең баш башлары чигүле ак киндер сөлгеләре, әниләрнең чулпылары, талир тәңкәләре, әтибабайларның түбәтәй-кәләпүшләре, уеннары-йолалары — җыеп әйткәндә, халкыбызның милли традицияләре, гореф-гадәтләре тәңкәләп, кадерләп салынган Рух вә Хәтер сандыгыдыр. Аны һич тә биктә тотарга ярамый — теләгәннәр ачсыннар, файдаланып калсыннар. Һәм... яңа хәзинәләр өстәп баетсыннар!

Роберт ӘХМӘТҖАН,
шагыйрь

Иншалла, барысы да булыр

«Төрек дөньясы» җәмгыятенең бурычы — бөтен дөньядагы төрки халыкларны сәяси, мәдәни яктан берләштерү ул. Шушы бурычны үтәү максатында без бер елдан артык инде Татарстан белән тыгыз бәйләнештә торабыз.

Хәзергә нинди эшләнде соң? Казан дәүләт педагогия институтының чит телләр факультетындагы төрек теле бүлегенә без дәреслекләр, җиһазлар белән булышабыз. Безнең җәмгыятьнең әгъзасы *Эрол Каймак* шушы институтта эшли.

Мин үзем Казанда берничә мәртәбә булдым. Студентлар төрек телен кызыксынып өйрәнәләр. II нче лицей мәктәбендә дә төрек телен яратып укыйлар. Педагогия институты карамагындагы бу лицейны да без дәреслекләр, җиһазлар белән тәэмин итеп торабыз. Бер-ике ай элек Казан дәүләт педагогия институты ректоры Р. Йосыпов, профессор З. Гатиятуллина һәм Эрол Каймак, Симферопольгә килеп, безнең җәмгыять әгъзалары белән очраштылар; педагогия институты каршында махсус төрек лицее ачу турындагы килешүгә кул куелды. Ул «Төрек дөньясы» җәмгыяте шефлыгында булачак. Төрек лицееның киләчәге әйбәт. Гомумән, Казанда төрек мәдәнияте үзәге оештырырга уйлыйбыз. Иншалла, Татарстан хөкүмәте, аерым алганда, Ленин районы администрация башлыгы Ә. Мөхәммәтзакиров ярдәменнән ташламасалар, төрек үзәге дә, лицей да ачылыр, дип уйлыйбыз.

Быел төрек теле бүлегендә укучы студентларны без Төркиягә төрек теле буенча стажировка узарга үзебезнең чыгымнар исәбенә чакырабыз. Төрек телен аеруча яхшы үзләштергәннәргә, бер еллык хәзерлек курслар узганнан соң, Стамбул университетында уку хокукын бирәчәкбез.

Хәлил АЧЫГУЗ,
«Төрек дөньясы» җәмгыяте рәисе урынбасары.

Читек, чүәк, түбәтәй...

Шундый бер риваятьне ишеткәнем бар: Болгар җиренә яу белән килгән юлбасарлар кинәт тукталып кала. Ни булган дисезме? Алар болгар сугышчылары аягында күннән бизәп эшләнгән читекне күреп хәйран калган. «Бу бер-бер хикмәттер, борылыйк булмаса», дип килгән юлларыннан китеп барганнар. Кайткач үз патшаларына әйткәннәр икән: «И, падишаһ, безне ярлыка син. Без аларны барыбер җиңә алмаган булыр идек»... «Ни өчен?» дип ярсулы сораган хаким. «Безнең аякта — чабата, ә алар әнә нинди читек кигәннәр», дип, үзләре белән алып кайткан бизәкле күн итекне чыгарып салганнар...

Әйе, борынгы бабаларыбыз элек-электән кул эшенә оста булган. Моннан мең еллар элек үк инде алар затлы күннән читек тегеп кигәннәр, чүәкләр ясаганнар... Арча милли аяк киемнәре тегү берләшмәсе әнә шул еракларадан килә торган традицияләрнең дәвамчысыдыр. Быел аның берләшмә булып оешуына 20 ел тулды. Ә берләшмә исә үзенең башлангычын Биектау районының Мүлмә авылындагы Тукай артеленнән ала. Ул исә 1932 нче елда төзелгән. Хәзер безнең коллектив ел саен төрлетөрле фасондагы 800 мең пар аяк киеме тегеп-чигеп чыгара. Милли түбәтәй цехы ачып җибәрдек. Аның да кабатланмас бизәкләре сатып алучыларны үзенә тартып тора. Читек, чүәк, түбәтәйләрнең 70 проценттан артыгы үзебездә кала. Төрле төбәкләрдә тупланып яшәүче милләттәшләребез үтенеченә дә колак салабыз. Алар заказы буенча Мари-эл республикасының Бәрәңге районына, Екатеринбургка, Уфа, Күкчәтау, Латвия, Төмән, Архангельск, Сахалин, Красноярск, Кемерово шәһәрләренә читек-чүәкләр эшләп җибәрдек.

Ләкин ил-дөнья күләмендәге икътисади кризис безнең эшчәнлеккә дә нык суга, әмма без югалып калырга уйламыйбыз. Яңадан-яңа чыганаклар эзлибез, үзебезнең чималларны эшкә җигәргә уйлыйбыз.

Коллективыбызга нинди генә җаваплы эшләр тапшырылса да, без аны намус белән башкарып чыгарга тырышабыз. Казанның Татар ашлары йорты, Г. Камал исемендәге Татар академия театры биналарының стеналарына игътибар иткәнегез бармы? Андагы күнгә чигеп эшләнгән матур-матур бизәкләрне безнең осталар иҗат итте. Киләчәктә без чит илләрдәге милләттәшләребез белән дә турыдан-туры элемтәләр урнаштырырга уйлыйбыз.

Илдус ГАЙНЕТДИНОВ,
Арча милли аяк киемнәре берләшмәсе директоры.




Рәсемдә: Арча милли аяк киемнәре берләшмәсе осталары Алия Гыймадиева (сулда), баш инженер Фаил Хәбриев (уртада), Ләйлә Шакирова.

Җиденчесе — Шәймиев

23 май көнне Казанда Татарстан халыкларының I корылтае булды. Һәм анда БМО каршында эшли торган Бөтендөнья рыцарьлар конфедерациясенең Халыкара парламенты президиумының почетлы әгъзасы булып сайланган Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевкә шушы Халыкара оешманың югары бүләкләре — «Ак Тәре», «Гаделлек һәм гуманизм өчен», «Зәңгәр тасмалы зур йолдыз» орденнары тапшырылды. Әлеге ике вакыйганың — Татарстан халыклары корылтае белән Халыкара парламент бүләкләрен илбашыбызга тапшыру тантанасының бергә туры килүе аеруча куанычлы. Төптәнрәк уйлап караганда, бер-берсенә тыгыз бәйләнгән, Татарстан халыкларының тату яшәве турында, Татарстанның бәйсез дәүләт буларак халыкара таныла башлавы хакында сөйли торган вакыйгалар болар.

Янә шунысы да очраклы түгел, минемчә: илбашыбыз Минтимер Шәймиев — бу Халыкара оешма тарафыннан югары бүләккә лаек булган милләттәшләребезнең җиденчесе. Моңарчы мондый бүләкләр белән зыялыларыбыз Сәлам Алишев, Рәзил Вәлиев, Әбрар Кәримуллин, Мирфатыйх Зәкиев, Айдар Хәлим, Равил Фәйзуллин бүләкләнгән иде. Менә җиденчесе — Татарстан Президенты.

Җиделе — бәхетле сан ул. Җидегән йолдыз. Салават күперенең җиде төсе, Җиде гөмбәзле Сөембикә манарасы. Менә рыцарьларыбыз да җидәү булды. Җидедән бәхет бар безнең.

Р. МИНҺАЖ.

Инде файдасын күрик

Нефтебез турында сүз кузгалса, ирексездән аның кызганыч үткәне күз алдына килеп баса.

Кара алтын, нәфис мехлар
Төяп бүләккә,
Теплоходлар дулкын ярып,
Китә үзәккә,—

дип җырлый идек. Шулай җырлый-җырлый без 2,6 миллиард тонна байлыгыбызны читкә озаттык. Республикадагы нефтькә кагылышлы бөтен эшләр белән чынлыкта партия комитеты идарә итте. Яңгыравыклы, ләкин асылда Татарстан халкын, нефтьчеләрне алдауга корылган лозунгларны бер-бер артлы коеп кына тордылар. Татарстанда чыгарылган бер тонна нефтьнең бәясе бер стакан газлы суга бәрабәр, дип сөйләүләр юкка гына булмады. Һәм, чынлап та, бер стакан газлы су биреп канәгатьләндерәләр безне.

Безнең промыселларга чит илләрдән вәкилләр күп килә. Элегрәк тә андый визитлар булды. Арада Канададан килгән кунакларның гаҗәпләнүләре әле дә күз алдында тора. Бөтен илдә әйдәп баручы промышленность үзәгенең бик тә кызганыч хәлдә яшәвен алар һич кенә дә акылга сыйдыра алмадылар.

Нефть ул — җир каны. Бу энергия чыганагын яңадан тулыландырып булмый. Безгә менә шуннан чыгып эш йөртергә, беренче чиратта, булган байлыкларыбызга хуҗаларча карау турында уйларга кирәк. Нефть запасларын бик сак һәм максатка ярашлы файдалану юлларын билгеләргә, шул ук вакытта Татарстан ихтыяҗларын алгы планга куярга тиешбез. Бу бөтендөнья практикасында шулай эшләнә.

Нефтькә таянып сөйләшүебезгә үртәлүчеләр, гаеп итәргә тырышучылар да очрап тора. Ләкин нефть — чын-чынлап та безнең халыкның таянычы һәм мактанычы. Без, хәтта башка бернәрсәбез булмаса да, бары тик нефть хисабына гына да тормышыбызны көйле итеп тота алабыз. Бервакыт «Известия» газетасы үзенең бер санында, Татарстанда чыккан нефть үз халкына калса, алар алтын тоткалы «мерседес»ларда гына йөрерләр иде, дип язып чыкты. Менә нәрсә ул нефть!

И. ЙОСЫПОВ

«ТатНИПИнефть» институты директоры урынбасары, геология-минералогия фәннәре докторы, профессор, Дәүләт премияләре лауреаты, атказанган фән эшлеклесе, Республика дәүләт советы әгъзасы.

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ • ВСЕМИРНЫЙ КОНГРЕСС ТАТАР • WORLD CONGRESS OF TATARS • КАЗАН • 1992 • QAZAN

Референдумда:

«Татарстан Республикасының Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы договорлар нигезендә коручы суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты булуына Сез ризамы!

ӘЙЕ!

ТУГАН ТЕЛ

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.
Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.
И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.
И туган тел! Синдә булган иң элек кылган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, ходам.

Г. Тукай

«КамАЗ»лар дөнья юлларында

«КамАЗ» автомобильләренең кукрәгендә койрыгын чәнчи-чәнчи ажгырып чабучы тулпар рәсеме. Татар халкы гомер-гомергә ат белән яшәгән, үзенең ашатучысы, киендерүчесе, яуда ышанычлы дусты итеп атны санаган. Шунлыктан халкыбыз арасында атка хөрмәт зур.

«КамАЗ» автомобиленең куәте 260 ат көчле. Иксез-чиксез юлларда, 1976 елның 16 февраленнән, ягъни беренче «КамАЗ» конвейердан төшкән көннән бирле бер миллионнан артык машина чыкты. Аларның нинди генә төрләре юк. Бүген баш конвейердан ун төрле автомобиль чыгарыла. Соңгысы — ике күчәрле «КамАЗ-4325» автомобиле. Йөк күтәреше аз гына кимесә дә, ул өч күчәрледән һич калышмый. Өстенлеге шунда: ул ягулыкны өч күчәрлегә караганда бер ярымга ким тота. Запас частьлар да азрак кирәк.

Ике күчәрле КамАЗ»лар Балтик буе илләрендә һәм җөмһүриятебездә уңышлы эшлиләр. КамАЗ конструкторлары «КамАЗ» вездеходын тагын да камилләштерү турында баш ваталар. «КамАЗ-4310» автомобиленең шассиен 6 тоннадан 15 тоннага чаклы йөк күтәрүгә җайлыйлар. Мондый автомобильләр урманчылар, нефтьчеләр, юл төзүчеләр өчен гаять уңайлы булачак, һәм чит илләрдән «Татра», «Магирус» автомобильләрен алуның хаҗәте бетәр.

Авыл хуҗалыгы йөкләренең 75 процентын «Камаз» автомобильләре ташый.

«КамАЗ» акционерлык җәмгыятендә йөк автомобильләре генә түгел, «Ока» җиңел автомобильләре, «К-20» маркалы кечкенә тракторлар, «Җигули», «Москвич» һәм «Запорожец» автомобильләренә запас частьләр һәм башкалар эшләнә. Хәзер кечкенә җиңел машиналар өчен яңа завод корыла. Быел камазлылар кечкенә литражлы 5 мең автомобиль эшләп чыгару өчен тырышалар.

Киләсе елдан техник яктан катлаулы әйберләр — агач эшкәртү агрегатлары һәм станоклар, газ плитәләре һәм яңартылган тагылма арбалар чыгарылачак. Тузан суырткычлар, бәйләү машиналары җитештерү күздә тотыла. Торак төзелешенә игътибар артты. Быел 7 мең квартираны сафка бирү планлаштырыла.

Татарстанның иң уңдырышлы җирләрендә урнашкан КамАЗ — бөтен дөньяга мәгълүм предприятие. Союз таркалганлыктан, СССР министрлыгы буйсынуында түгел ул хәзер. Әмма күпме сүз кузгатылса да, аның җөмһүриятебез юрисдикциясенә күчкәнгә карап, колачы һич тә тараймас, абруе төшмәс иде. Әбит КамАЗның да туып-үскән урыны барыбыз өчен уртак ватан булган шушы Татарстан лабаса! Җөмһүриятебезгә күбрәк табыш китерүдән аның эшче-хезмәткәрләре һич тә оттырмас.

СҮЗ—ЧИТ ИЛ БИЗНЕСМЕННАРЫНА

Питер Бонфилд

Бөекбританиянең «Интернэйшнл Компьютерс Лимитед» компаниясе президенты.

— Безнең компания 70 илдә электрон-хисаплау технологияләре, күптөрле компьютерлар эшләп чыгара. Мәскәүдә вәкиллегебез оештырылуга 25 ел. Һәм менә Казанда да үзебезнең уртак предприятиебезне ачарга булдык. Казан электрон-хисаплау системасы берләшмәсе белән берлектә шул турыда килешү төзелде.. Уртак предприятиедә эшләнгән технология сәламәтлек, хокук саклау, сәүдә оешмаларында, шулай ук башка предприятиеләрдә киң куллану табачак.

Гөрри Олкотт

«Полярные медведи» Америка корпорациясе президенты.

— Безнең корпорациягә Американың йөздән артык төрле компанияләре керә. Татарстанда минем белән бергә Флорида штатыннан бизнесменнар да килде. Без Казаннан тыш Чаллыда, Түбән Камада, Алабугада, Чистайда, нефть һәм авыл районнарында булдык. Максатыбыз — Татарстан җирендә уртак сәүдә-икътисади корпорация булдыру. Унга якын җирле предприятие белән килешүләр төзелде инде. Казан оптика-механика заводы берләшмәсеннән Америка базарында һәм башка илләрдә сату өчен төрле оптика әйберләре алачакбыз. «Татарстан авиалиниясе» һәм «Дельта» авиакомпанияләре арасындагы килешү нәтиҗәсендә Майами һәм Казан арасында даими рейслар ачыла. «Заря» фабрикасы җитәкчеләре Чаллыда шоколад җитештерү предприятиесе төзү турындагы тәкъдимебезне хуплап каршы алды.

Балык Бистәсе районында ау эшләрен оештыру, йортлар, минераль су заводлары төзү турында уйлыйбыз. Без Татарстан җирендә хәтта нефть эшкәртү заводы төзергә әзербез.

Илдар Агиш,
Америка татарлары ассоциациясе президенты

Илхан Айдагул,
«Идел-Гирейдинг» корпорациясе президенты. Америка татарлары ассоциациясе 1927 елда оеша.

Илдар: Минем Казанга килүем өченче тапкыр инде. Татарстанда коммерция эшләрен җәелдерү өчен мөмкинлекләр зур. Безне бигрәк тә станокта эшләнмәгән, кул белән җитештерелгән әйберләр кызыксындыра. Биредә халык эшчән, белемле, кулдан эш килешле. Тик дөньяга караш үзгәрергә, яңача уйларга, яңача эшләргә кирәк. Бөтендөнья татар конгрессында чит илләрдә яшәүче татарларның бер оешмасы, әйтик, милли лига төзелсә яхшы булыр иде. Бөтен дөньядагы милләттәшләребезне берләштерү үзәге — Татарстан-Казан гына була ала.

Илхан: Татарстанның күп кенә завод-фабрикаларында булып яңа технология кертергә сөйләштек. «Компрессормаш», «Вакуummаш», «Спартак», «Союз», Түбән Кама «Шин» предприятиеләрендә очрашуларыбыз файдалы булды. «Вакуммаш» белән безнең технология буенча тузан суырткычлар җитештерү буенча килешү төзелде. Безгә Россия белән эшләү бәлки җиңелрәк тә булыр иде. Ләкин без үз Ватанабызда үз милләтебез белән татарча сөйләшеп эш уздырмакчы булабыз. Чит илләрдә дә милләтебезнең мөмкинлекләрен белсеннәр иде. Теләгем шул: башка илләрдә яшәүче татарлар да бездән үрнәк алып, шундый ук арадашчылыкка, дуслыкка тотынсыннар иде.

ФӘНДӘ ҺӘМ СӘНГАТЬТӘ

Җөмһүриятебездә бүгенге көндә барлыгы 800 дән артык фән докторы эшли. Шуларның 263е — татар. Бу олуг фәнни дәрәҗәгә ирешүче милләттәшләребез арасында 33 хатын-кыз да бар.

• • •

Татарстанның хәзер үз фәннәр академиясе бар. Аның беренче президенты итеп Мансур Хәсәнович Хәсәнов сайланды. Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзаларыннан 22се — үз милләтебез галимнәре. Менә кемнәр алар: Наил Әхмәтов, Мирфатыйх Зәкиев, Әбрар Кәримуллин, Мирза Мәхмүтов, Рафыйк Нәфыйков, Диләрә Тумашева, Миркасыйм Госманов, Мансур Хәсәнов, Диләвер Зәбәеров, Газим Идрисов, Марс Михайлов, Илдус Закиров, Тәлгать Сиражетдинов, Илтазар Терегулов, Ирек Фәхретдинов, Камил Вәлиев, Роальд Сәгьдиев, Кеф Салихов, Наил Сәхибуллин, Шамил Чабдаров, Әхмәт Мәзгаров, Ринат Сәйфуллин.

• • •

Җөмһүриятебез шулай ук музыка, җыр-бию һәм сәнгать өлкәсендә дә исемнәре халык йөрәгенә кереп калган күренекле шәхесләргә бай.

Татарстанның халык артисты, Г. Тукай бүләге лауреатлары Илһам Шакиров, Ринат Ибраһимов, Әлфия Авзалова, Зилә Сөнгатуллина, Хәйдәр Бигичев, СССРның халык артисты Азат Аббасов, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклеләре композитор Әнвәр Бакиров, Фасил Әхмәтов, сәхнә осталары — СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров, Татарстанның халык артистлары Равил Шәрәфиев, Ринат Таҗетдинов, биючеләр — Татарстанның халык артистлары Ирина Хәкимова, Нинель Юлтыева, СССРның халык рәссамы Харис Якупов, һәм башкаларның исемнәре Татарстаныбызда гына түгел, чит илләрдә дә яхшы таныш.

Киләчәге матуррак тагын да

Фәтхетдин ХӘЙРЕТДИНОВ,
Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясе директоры

Бүгенге көндә Татарстанда барлыгы 19 татар гимназиясе һәм бер татар лицее эшли. Шуларның 9ы башкалабыз Казанда. Чаллыда — 2, Зәйдә — 1, Әлмәттә — 1, Алабугада — 1, Азнакайда — 1, Түбән Камада — 1, Зеленодольскида — 1, Түбән Кама районында бер гимназия һәм Кукмара районының Зур Сәрдек авылында лицей ачылды.

1992-93 уку елында яңадан 7 татар гимназиясе ачылу планлаштырыла. Казанда — 5не, ә калган икесен районнарда ачу күздә тотыла.

Казанның Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче гимназиясе ачылганга ике ел вакыт үтте. Биредә барлыгы 520 бала белем ала. Фәннәр нигездә ана телендә укытыла. Гимназиядә кайбер лекцияләрне Казан дәүләт университеты укытучылары һәм Татарстан фәннәр академиясе галимнәре — Әбрар Кәримуллин белән Сәлам Алишев алып баралар. Алар укучыларны татар әдәбияты һәм татар халкы тарихы белән таныштыралар.

Гимназиядә укучылар 2 нче класстан башлап гарәп, кытай һәм инглиз телләре өйрәнәләр. Компьютерлар белән җиһазланган класста балалар үзлекләреннән төрле фәннәр үзләштерәләр. Моннан тыш, гимназия базасында яңа уку елыннан Төркиянең Истанбул шәһәрендәге ир балалар лицееның филиалы ачылачак. Әле шушы арада гына гимназиядә аның мөдире Фәтхулла Кочар булып, гимназиянең мөмкинлекләре белән танышып китте. Филиалга укучылар 5 нче класстан кабул ителәчәк. Гимназиядә 9 нчы сыйныфны тәмамлаганнан соң бу балалар укуларын Истанбулдагы лицейда дәвам итәчәкләр, ә аннан соң инде Төркия университетларына имтихан тотачаклар. Бу мәктәпкә барлыгы 90 укучы кабул ителә.

Кыскасы, милләтебезгә һәръяктан камил булган, укымышлы, белемле зыялылар тәрбияләү өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Укытучылар, тәрбиячеләр коллективы моның өчен бөтен көчен, белемен һәм тырышлыкларын сарыф итә. Нәтиҗә күз алдында: узган уку елында гимназияне тәмамлаган 60 тан артык укучының 40 тан күбрәге бүген җөмһүриятебез югары уку йортларында белем ала. Гимназиянең бүгенгесе матур, ә киләчәге матуррак тагын да.

Татар дөньясында нинләр бар?

ЧИЛӘБЕ. Татарлар элек-электән чигү эшен бик яратканнар. Үзенең күңел түрендәге бизәкләрне тукымага, күнгә, металлга төшергәннәр. Чиккән калфаклар, читекләр, кулъяулыклар, сөлгеләр... Халкыбызның бу шөгыле хәзергәчә сакланып калуы бик куанычлы хәл.

Шәһәрнең Ш. Бабич исемендәге татар-башкорт китапханәсендә татар халкының әлеге төр иҗатына багышланган күргәзмә оештырылды. Аның кайбер үрнәкләре төрле гаиләләрдә сакланып калган борынгы ядкярләр иде. Күргәзмәне һәр милләт кешесе кызыксынып карады.

ОРЕНБУРГ. Биредә «Яңа Ватан» исемендә атналык иҗтимагый газета чыга башлады. Аның беренче саннарын бөтен татар җәмәгатьчелеге: «Төкле аягың белән!» дип каршылады.

Газетаның «Яңа Вакыт» дип аталуы очраклы гына түгел. «Вакыт» дигән татар газетасы биредә 1906 елдан 1918 елга кадәр чыгып килә. Анда Дәрдмәнд, Г. Тукай, Җ. Вәлиди, Й. Акчура, Г. Ибраһимов, Ш. Камал әсәрләре басыла. Газета 12 ел халкыбызга хезмәт күрсәтә.

НИЖНИЙ НОВГОРОД. Татар мәдәнияте җәмгыяте рәисе, философия фәннәре кандидаты А. Орлов өлкәдә милли мәдәниятны үстерү буенча төп юнәлешләр проектын эшләде. Автор анда «Нижний Новгород крае тарихы» дигән китабында татарлар турында махсус бүлек булдыруны күздә тота. Аннары Казан, Мәскәү, Уфа, Ульяновск һәм башка шәһәрләр галимнәре белән берлектә, фәнни конференция уздыру планлаштырыла. Борынгы мәчет һәм мәдрәсәләргә архитектура һәйкәле статусы бирү дә карала. Шулай ук китапханәләрдә милли бүлекләр ачу, татар мәдәнияте фестивальләре уздыру күздә тотыла.

УФА. Җир шарының кайсы гына төбәгендә яшәсәң дә, халык әйтмешли, бал белән май эчендә йөзсәң дә, туган-үскән җир сагындыра. Сиксән яшен тутырып килүче Сәдит ага Шәмсулланың Туймазы районына кайтып яши башлавын шулай гына аңлатырга мөмкин. Ә бит ул чит җирләрдә 63 ел яшәгән. Әфганстан, Пакистан, Һиндстан, Австралиядә булган. Моның иң күп өлешен Мельбурн шәһәрендә уздырган.

Сәдит ага Шәмсулла инглиз, гарәп, үзбәк, фарсы, урду телләрендә әйбәт сөйләшә, туган телен дә онытмаган. Бомбей кунакханәләренең берсендә аш пешерүче булып эшләгәндә ул Грис исемле кызга өйләнә. Алар дүрт бала тәрбияләп үстергәннәр.

НОВОСИБИРСК. Мөселманнар җәмгыяте өлкәдә беренче мәчет салдыру хәстәрен күрә. Аның бөтен чыгымы 700000 сум булыр, дип көтелә. Хәзер әлеге изге максат өчен акча туплана.

«Тургай» исемендәге татар җыр һәм бию ансамбле коллективы шушы эшкә иң беренче булып үз өлешен кертте. Бишәр сумлык хәерхак билетларын сату да мәчет фондын тулыландыруны күздә тота.

ПЕНЗА. Өлкәдә һәм әлеге шәһәрдә барлыгы 81 меңнән артык татар яши. Әмма шушы көнгә кадәр аларны берләштерүче оешма юк иде. Хәзер андый җәмгыять төзелде. Аның исеме — «Якташлар». Җәмгыятькә Нәсыйх Гыймади җитәкчелек итә. Милли үзаңны уятуда, халкыбызның гореф-гадәтләрен яңадан кайтаруда зур көч булуын аңлыйлар биредә.

КЕМЕРОВО. Өлкәдә 100 меңнән артык татар яши. Әмма озак еллар дәвамындагы сәясәт нәтиҗәсендә биредә күпләр үзенең туган телен оныткан, динен, мәдәниятын югалткан. Боларны кире кайтару өчен, зур көч, тырышлык кирәк. Билгеле, Татарстанның ярдәменнән башка берни барып чыкмый.

Өлкәдәге татар иҗтимагый үзәге Татарстан Республикасына мөрәҗәгать иткән иде. Нәтиҗәдә ике арада килешү төзелде. Ул сәүдә-икътисади һәм милли-мәдәни хезмәттәшлекне күздә тота. Димәк, Кемерово татарларының уянуына да ышаныч бар.

ИЖЕВСК. Удмуртиянең Балезин районында татарлар яши торган Кистем авылы бар. Удмурт, рус авыллары арасында чолганып яшәсә дә, мондагы татарлар туган телләрен дә, гореф-гадәтләрен дә онытмыйлар.

Биредәге урта мәктәптә татар телен һәм әдәбиятын укыту торгынлык елларында да туктатылмады. Мәчет тә ябылмады авылда. Кистем клубында еш кына «Туган тел» кичләре үткәрелә. Ул көнне клубта басып торырга да урын булмый.

Н. БУЛАТОВ
туплады.

Сез кайларда, татар угъланнары

Марис НАЗИРОВ сүзләре
Рим ХӘСӘНОВ музыкасы

Чорлар аша әрнеп үткәннәргә —
Халкым тарихына карадым:
Җил-давыллы язмыш йомычкадай
Җилтерәткән милләт корабын.

Сез кайларда, татар угланнары,
Җан асрыйсыз кайсы илләрдә?
Кан тартмаса, бәлки, җан тартадыр,
Сөйләшәсез нинди телләрдә?

Ярдан-ярга кораб сугыла да
Керә кабат упкын-диңгезгә,
Фәләстиннәр кебек бәйсез илен —
Үз дәүләтен йөри ул эзләп.

Сез кайларда, татар угъланнары,
Кайсы кыйтга, кайсы җирләрдә?
Кан тартмаса, бәлки, җан тартадыр,
«Әнкәй!» — дисез нинди телләрдә?

Дулкын куган кораб адашмаска
Акчарлаклар булып ялварам:
«Җил-давылда маяк кабызыйк без
Очрашырга ерак ярлардан!»

Сез кайларда, татар угъланнары,
Калдырасыз мирас кемнәргә?
Кан тартмаса, бәлки, җан тартадыр,
Җыр җырлыйсыз нинди телләрдә?

МӘШҺҮР МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ

Шахматчы Гата Камский АКШта яши. Ул үзе Свердловскида туган, Өч яшеннән шахмат уйный. Соңгы елларда Ленинградта яшәде. Уен осталыгын чарлар, шахмат ярышларында катнашу мөмкинлекләрен арттыру өчен ике ел элек әтисе белән АКШка күчеп китәргә мәҗбүр булды. Яшьләр арасында күренекле шахматчы булып танылган Гата күптән түгел генә Германиянең Дортмунд шәһәрендә үткәрелгән халыкара шахмат бәйгесендә хәзерге дөнья чемпионы Г. Каспаровны отты.

●

Әстерханда туып үскән футболчы Ринат Дасаев — СССРның атказанган спорт мастеры. Озак еллар «Спартак» һәм ил җыелма командасының төп капкачысы булды. Хәзерге вакытта Испания футбол командаларының берсендә уйный.

Ростов егете Вагыйз Һидиятуллин да — СССРның атказанган спорт мастеры. Ул да Ринат кебек «Спартак»та уйнады. Ярымсакчы иде. Хәзерге вакытта Франциядәге бер футбол командасының данын яклый.

●

Роальд Сәгъдиев — дөньяга танылган физик. Соңгы вакытта Мәскәүдәге Космик тикшеренүләр институтының директоры булып эшләде. Казанда туып-үскән мәшһүр якташыбыз хәзерге вакытта Америка Кушма Штатларында яши. Анда гыйльми эшләр белән шөгыльләнә, студентларга лекция укый.

Мәчетләребез. Европа һәм Себер мөселманнары диния нәзарәте башлыгы мөфти Тәлгать Таҗетдин.

Сабантуй　　Сабантуй　　Сабантуй

Берләшик, туганнар

Мәхмүт ГӘРӘЕВ,
армия генералы, хәрби фәннәр докторы, профессор

Мин халкым алдында һәрвакыт баш иям. Тарихта ачы язмышка дучар ителсә дә, ул сыгылып, сынып калмаган. Барлык авырлыкларны һәм киртәләрне җиңеп, үз телен саклаган, әдәбиятын, сәнгатен һәм мәдәниятен үстергән. Хәрби кеше буларак шуны әйтим: татарларның хәрби өлкәгә керткән өлешләре дә бик зур. Бу Бөек Ватан сугышы елларында аеруча калку чагылды. Ә бит Кораллы Көчләрнең нинди дәрәҗәдә булуына карап элек-электән дәүләтнең абруе билгеләнгән. Мылтыклы солдатка һәркайда иң зур хөрмәт күрсәтелгән.

Халкымны ачы язмышка дучар итүгә патша Россиясендәге милли сәясәт зур роль уйнады. Кызганычка каршы, Октябрь революциясеннән соң да татарларга милләт буларак үсеш юлында күп төрле киртәләр куелды, шовинистик басым ясалды. Әлеге сәясәт татар халкын бик кыен хәлдә калдырды, аның күп кенә рухи байлыкларын югалтуга китерде.

Мондый авыр хәлләрдән бары тик тупланып, көчләрне берләштереп кенә чыгып була. Һәм әлеге көрәштә интеллигенция алдан әйдәп барырга тиеш. Кызганычка каршы, безнең язучылар, фән һәм сәнгать эшлеклеләре арасында еш кына татулык булмау күзгә ташлана. Ә шулай икән, таркалуыңны көт тә тор инде. Халык язмышы турында сүз барганда аерым төркем мәнфәгатьләре беренче урынга чыгарга тиеш түгел. Татарларны дөнья күләмендәге югары баскычларга күтәрик дисәк, берләшик, тупланыйк, туганнар!

Телебезне саклауда Татарстан читкә таралып утырган милләттәшләребезгә дә ярдәм итәргә тиеш. Татар мәктәпләре ачуда, аларны дәреслекләр белән тәэмин итүдә, мәдәният белгечләре җибәрүдә аларның башка таяныр урыннары юк. Шулай ук Татарстанда яшәүче бүтән милләтләр дә онытылмаска тиеш.

Татарстанга — борынгы бабайлар нигезенә кайтырга теләгән татарларга кулдан килгәнчә ярдәм итәсе иде. Моның өчен, минемчә, чит илләрдә яшәүче бай милләттәшләребезне тартып, махсус фонд булдырырга кирәк. Мин Татарстан Республикасының куәтле, бәйсез булуын телим. Моңа ирешүдә халкыма уңышлар юлдаш булсын иде.

Иң күркәм бәйрәмебез

Менә тагын сабантуйлар җитте. Авылларда халык яңадан табигатьнең иң ямьле урыннарына — инеш-елга тугайларына, болыннарга, яланнарга агыла. Биек колга очындагы чиккән сөлге һәркемне үз тирәсенә кызыктамаша карарга чакыра. Их, күңелле безнең сабантуйлар! Татарча көрәше үзе генә дә ни тора бит!

Халкыбыз көчле-куәтле кешеләрне элек-электән хөрмәт иткән. 922 елда борынгы Болгар дәүләтендә булган гарәп сәяхәтчесе Ибн-Фадлан һәм Идел буена 1131 елда килгән Әбү Хәмид әл-Гарнати бу якларның Алып батырлары турында сокланып сүзләр язып калдырганнар.

Үзенең бәет-хикәятләрендә татар халкы сабантуй батырын гади хезмәт кешесе итеп сурәтләгән. Ул, көч-куәтен тагын бер тапкыр раслап, мәйданнан иң зур бүләген — тәкәне югары күтәреп чыккан. Шунда аңа яшь киленнәр чиккән башлы сөлге, кулъяулык та бүләк иткәннәр. Бу матур гадәт хәзергәчә сакланып калган.

Сабантуйның бик борынгы бәйрәм булуын аның атамасы ук күрсәтеп тора. В. Радлов, К. Фукс, С. Токарев кебек күренекле рус галимнәре дә бу бәйрәмнең килеп чыгышы язгы кыр эшләре белән бәйле булуын күрсәткәннәр.

Казанда атаклы «Шәрыкъ» клубы революциягә кадәр сабантуйларны ямьле итеп уздыру өчен күп тырышлык куйган. Аның әһелләре, беренчедән, милли бәйрәмебезнең борынгы традицияләрен саклауны максат итеп куйсалар, икенчедән, аны күңел ачулар һәм әдәби кичәләр белән баетканнар. Әмма сабантуйларга һәркем дә бердәй карамаган. Мәсәлән, Оренбург мулласы Әбү Сәгыйт эш-Шәдави сабантуй белән җыенны тыярга чакырып чыгышлар ясаган. Аларны «шайтан туе» дип атаган.

Хәзерге сабантуй татарлар яши торган һәр төбәктә уздырыла. Мәскәүнең Измайлов паркындагы сабантуй турында кем генә белми икән? Санкт-Петербургта ул Выборг ягында уза. Ташкент, Уфа, Әстерхан шәһәрләре, Самара, Ульяновск, Оренбург, Пермь, Төмән, Кемерово, башка өлкәләрдә язгы чорда сабантуйның чиккән сөлгесе озын колга башында җилфердәмичә калмый.

Сабантуй темасы әдәбият сәнгать осталарына да рух өсти, алар иҗатына киң үтеп керә. СССРның халык артисты, Социалистик Хезмәт Герое композитор Нәҗип Җиһанов үзенең 2 нче симфониясен «Сабантуй» дип атады. Әлеге тема танылган композиторларыбыз З. Хәбибуллин, Ф. Әхмәтов, Ш. Шәрифуллин әсәрләрендә дә чагылыш тапты.

Тренерларыбыз һәм батырларыбыз кулында соңгы вакытка кадәр татарча көрәшнең нигезләрен аңлаткан бер генә кулланма да юк иде. Танылган көрәш остасы, тренер һәм галим, Казан дәүләт ветеринария институтының физик тәрбия кафедрасы мөдире Мәгаз Сәхәбетдиновның «Татарча көрәш» дип исемләнгән китабы һәркем өчен кыйммәтле кулланма булды.

Дамир ШӘРӘФЕТДИНОВ.

Бу — сәяси бәйрәм

Милли конгрессның нинди зур вакыйга булуын әйтеп торасы юк инде. Ул безнең традициягә әверелергә тиеш. Чөнки бу конгресс бәйсезлек юлыннан атлаучы Татарстанга кардәшләребез аша киң дөньяга чыгарга, яңа эшлекле дуслар эзләп табарга, җыеп әйткәндә, сәяси бәйрәмгә әверелергә тиеш. Аның бөек миссиясен мин нәкъ менә шунда күрәм дә.

Корылтайлар арасында татар халкының мәгърифәтен үстерү турында кайгыртучы бер даими орган оештырылыр, ул милли хәрәкәтебездәге экстремизмны киметергә булышыр, хөкүмәтебезнең бөтентатар халкы музеен — мәдәни үзәген ясарга, дигән бик күптәнге кирәкле карарын тормышка ашырырга ярдәм итәр, дигән өметтә калам.

Фәндәс САФИУЛЛИН,
Татарстан халык депутаты.

Халык әйтсә, хак әйтә

Ил илгә сыяр, өй өйгә сыймас.
Бердәм өйдә бәрәкәт бар,
гаугалы өйдә һәлакәт бар.
Дуслыкны акчага сатмыйлар.
Дуслык ашта беленми, эштә
беленә.
Дус үләр, дуслык үлмәс.
Кош — канаты белән, кеше дус-
иш белән.
Дус килгән көн — бәйрәм көн.
Ялгыз калган — ялкынсыз янган.
Дөнья — базар, базарда күп
йөргән азар.
Өйдәге уй базарга ярамас.
Батыр яуда беленер, телчән
дауда беленер.
Теле бозыкның күңеле бозык.
Агай, алдан сагай.
Кергән җиреңне карап кер.
Суга каршы йөзмә, җилгә
каршы төкермә.
Майдан ботка бозылмый.
Агач җимеше белән, кеше эше
белән.
Кошның матурлыгы төсенә
карап:
кешенең матурлыгы эшенә
карап,
Иш ишен табар.
Кәкре белән бөкре бертуган.
Арсланнан арслан туар.
Тумаган тайның атланып
билен сындырма.
Алты ай эшлә, унике ай аша.
Игә белгән иген ашар,
игә белмәгән ниен ашар.
Сабанда тирләмәсәң,
ындырда чирләрсең.
Кызлы өйдә кадер бар.
Кыз чагым — солтан чагым.
Егет булсаң, җилек бул,
суда йөзгән сөлек бул.
Алтын йөзекләр сынмас,
дәртле егетләр тынмас.

Сокланып кайттым

Александр ОРЛОВСКИЙ,
фермер, Киров өлкәсе

Татарстанга мин фермерлар эшчәнлеге белән танышырга килгән идем, бигрәк тә сарыкчылык тармагында эшне яңача оештыру мәсьәләләре кызыксындырды. Һәм мин тәҗрибә өйрәнү барышында Татарстанда яшәүчеләр белән әңгәмәләрдә бернинди дә киеренкелек, үземә карата игътибарсызлык тоймадым. Киресенчә, татар халкының кунакчыллыгы, ярдәм итәргә әзер торуы мине нык сокландырды. Ул соклануымны һич яшерә алмыйм. Урамнарда да дорфа кыланган, мыскыллау сүзе әйткән кешене очратмадым. Татарлар һәм урыслар, башка милләт вәкилләре арасында дустанә мөнәсәбәт тойдым.

Шәһәр кибетләрендә мине ашамлыкларның төрле һәм бездәгегә караганда арзанрак булуы шатландырды. Аннан авыл эшчәннәренең тырышлыгына сокландым. Казаннан тәҗрибә өйрәнеп, күңел тынычлыгы белән кайтып киттем, Татарстан халкына ихлас күңелдән уңышлар телим.

ТАТАР ДӨНЬЯСЫНДА НИЛӘР БАР!

КАМЧАТКА. Бу ярымутрауда яшәүче 480 мең кешенең 10 меңе татарлар. Алар тырышлыгы белән Татарстан Республикасы арасында дуслык җепләре ныгый. Биредән читкә чыгарыла торган төп товар — балык. Татарлар әлеге тармакта күпләп эшлиләр. Алар эшчәнлекләре белән аерылып торалар.

Ике арадагы күрешүләр нигезендә, Камчаткадан Татарстандагы кошчылык фабрикаларына һәм җәнлек фермаларына балык һәм балык оны җибәреләчәк. Кибетләргә балык консервалары озату да каралган. Моннан тыш «Мелита» акционерлык җәмгыятенә диңгез җәнлекләре тиресе дә китереләчәк әле.

ҺӘР ЕЛ САЕН АНЫ ХАЛКЫБЫЗ КӨТЕП АЛА. БИРЕДӘ ӘНӘ ШУЛАЙ КӨРӘШӘЛӘР, ЯРЫШАЛАР, КҮҢЕЛ АЧАЛАР.

«ВАТАН» МИЛЛӘТТӘШЛӘРНЕ ҖЫЯ

Бер-берләреннән читтә яшәүче аерым туганнарның, дуслар, танышларның үзара аралашуы, хат алышу, кунакка чакырышу, төрле ил кешеләренең мәдәни ярдәм итешүе — болар бар да халык дипломатиясенә караган күренешләр. «Ватан» җәмгыяте әнә шул бәйләнешләрне оештыручы бер мәркәз ул.

«Ватан»ны оештыру җыелышында аның президенты итеп академик Мирза Мәхмүтов, урынбасары итеп Дамир Гыйсметдинов сайланды.

Бер-бер артлы туып торган авырлыкларга, каршылыкларга карамастан, соңгы ике ел дәвамында «Ватан» телгә алып сөйләрдәй күркәм генә эшләр башкарды. Җәмгыять чакыруы буенча чит илләрдә яшәүче милләттәшләрдән йөздән артык кеше Казанда (бер өлеше Татарстан районнарында) булып киттеләр. Аларның байтагы 1990 һәм 1991 елларның җәендә милли бәйрәмебез Сабантуйга чакырылган иде. Узган ел үткәрелгән халыкара «Нәүрүз чибәре» исемле конкурс та күңелле бер вакыйга булып истә калды. Австралиядән килгән бер төркем татар яшьләре Казан университетында берничә ай дәвамында туган тел буенча дәресләр алып, мәдәни оешмалар белән элемтәләр урнаштырып киттеләр. Узган ел җәй азагында «Ватан» җәмгыяте һәм Төркиядәге милләттәшләребез Фәрит Бичури тырышлыгы белән Татарстан көймәчеләре, беренче мәртәбә халыкара ярышларда катнашып, республикабыз байрагы астында чыгыш ясадылар. Үткән елда Алманиянең Бавар телевидениесе Татарстан турында документаль фильм төшереп киткән иде. Аны Аурупа илләрендәге миллионлаган тамашачыларның кызыксынып караганнары мәгълүм. Бу фильмны эшләү дәвамында «Ватан» җитәкчеләренең дә ярдәме аз булмады. Җәмгыять булышлыгы белән төп ватаннары Татарстанда булып киткән милләттәшләрнең күбесе сәүдәгәрләр һәм журналистлар, галимнәр һәм дин әһелләре булуын да әйтеп үтик. Аларның кайберләре «Ватан» әгъзалары буларак җәмгыять эшчәнлегенә самими күңелдән ярдәм күрсәтәләр. Шуларның берничәсен рәхмәт хисе белән телгә алыйк: «Азатлык» радиосының танылган журналистлары Фәридә Хәмит, Фәрит Иделле (Алмания), бизнесменнар Фәрит Бичури (Төркия), Илдар Агиш, Равил Сәләхмәт (АКШ), Рөстәм һәм Сәгыйт Садрилар (Австралия).

«Ватан» башкарган эшләр шактый җыела, алай да аның эшләячәк эшләре күп тапкыр артыграк. Җәмгыятьнең алдагы планнарында татарлар торган илләргә милли кинофильмнар, видеокасеталар, музыкаль язмалар җибәрү, Татарстан сәнгать осталарының концертларын чит илләргә ешрак күрсәтү эшләрендә булышу, гомерләре мөһаҗирлектә үткән татар галимнәре һәм язучыларының мирасларын җыю, туплау мәшәкатьләрен уртаклашу, коммерция һәм бизнес дөньясыннан да читтә тормыйча, уртак ширкәтләр булдыруда катнашу кебек күп тармаклы эшләр каралаган.

Гаделлек хакында әйтергә кирәк, «Ватан» үзе генә хәл итә алмастай проблемалар да аз түгел. Ул әлегә матди ярдәмгә мохтаҗ, эшләрне уңышлы алып барыр өчен кайбер ширкәтләрдән кергән хәйрия ярдәме генә җитми, монда безнең хөкүмәтнең бу җәмгыятьне үз канаты астына алуы, аңа даими булышуы зарур.

Илбарис НАДИРОВ,
«Ватан» җәмгыяте әгъзасы.

Баш мөхәррир сүзе

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»— ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ

Мөнир ӘҺЛИУЛЛИН,
Татарстан халык депутаты.

Хөрмәтле милләттәшләребез!

Моннан 75 елга якын элек «Эш» исеме белән чыга башлаган газетабыз республикабыз халкы белән бергә авыр, катлаулы юл үтте. Ул Татарстан җөмһүрияте белән бергә туды, аның елъязмачысы булды. Татарстан җөмһүриятенең ничәмә-ничә буыны кешеләренә мәгърифәт өләште. Халкыбызның олы җиңүләрен зурлады, кимчелекләргә, житешсезлекләргә борчылды.

Татар халкының нинди генә бөек уллары язышмаган да, эшләмәгән бу газетада! Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимов, Хәсән Туфан, Муса Җәлил, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Бакый Урманче... Газета бөек акыл ияләренең якты идеяләрен эшчән халкыбыз рухы белән бәйләп килде.

Җөмһүриятебезнең иҗтимагый, сәяси һәм икътисади тормышындагы үзгәрешләргә карап, газета төрле елларда төрле исемнәр белән чыкты: «Эш», «Татарстан», «Татарстан хәбәрләре», «Кызыл Татарстан», «Совет Татарстаны», «Социалистик Татарстан». 1992 елның 25 февраленнән «Ватаным Татарстан» дигән исем белән чыга башлады. Аны оештыручылар: Татарстан Югары Советы Президиумы, Татарстан хөкүмәте һәм редакция коллективы. Үзенең мөстәкыйльлеге өчен көрәшүче Татарстан — үз территориясендә яшәүче күпмилләтле халыкның уртак Ватаны ул. Бер үк вакытта Татарстан — 7 миллион татар халкының рухи Ватаны да. Бу турыда аксакал әдибебез Әмирхан Еникидән дә матуррак итеп, күңелдән үткәреп әйтеп булыр микән!

«Һәр халыкның, кайларда гына яшәвенә карамастан, күз текәп торган төп Ватаны һәм рухи каласы була. Әйтик, урысның Россия дигән Ватаны һәм Мәскәү дигән изге каласы бар. Әрмән һәм грузин, үзбәк һәм таҗикларның да шундый рухи калалары бар. Билгеле инде, татар кешесенең дә, кайда гына яшәмәсен ул, Татарстан дигән Ватаны, Казан дигән рухи мәркәзе булырга тиеш», дип язды ул.

Бөтен татар халкының рухи Ватаны нәкъ менә Татарстан булганга Бөтендөнья татар конгрессы җөмһүриятебездә үтә дә инде. Бөтен татар халкының уртак трибунасы булган газетаны «Ватаным Татарстан» дип исемләү дә табигый. Газета 1991 елның 8 августында гомумтатар газетасы буларак теркәлде, һәм ул 7миллионлы татар халкының уртак трибунасына әверелде.

Хөрмәтле милләттәшләребез!

«Ватаным Татарстан» газетасы бүген җөмһүриятебезнең тулы бәйсезлеге өчен көрәшнең алгы сызыгында. Гомумтатар газетасы буларак, анда җөмһүриятебездән читтә яшәүче милләттәшләребезнең тормыш-көнкүрешен чагылдырган язмаларга да киң урын бирелә. Чөнки аны республикабыздан читтә дә 10 меңнән артык гаилә алдыра.

Без киләчәктә дә, кадерле милләттәшләребез, Сезне үзегезнең яраткан газетагыз — «Ватаным Татарстан» газетасының даими укучылары булып калырсыз дип өметләнәбез.

Сез кайда гына яшәсәгез дә, бу газетаны яздырып ала аласыз. Аңа язылу «Международная книга» акционерлык җәмгыятенең барлык илләрендә эшләп килүче «Совинпериодика» фирмасы контрагентлары аша гамәлгә ашырыла. Газетаның индексы: 54123.

Авыл яшәсә, ил яшәр.

Баш мөхәррир — МӨНИР ӘҺЛИУЛЛИН.
Бу санны бизәүчеләр: рәссам И. Рәхимов, фотохәбәрчеләр Д. Бунтуков, Р. Мансуров, М. Медведев, А. Андронов.
Бу санны оештыручылар: З. Шәфигуллин, Г. Кәримуллина.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты типографиясендә басылды. Заказ В-239 Индексы 54123